**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**24.03.2025** **№ 135**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Сармаш-Баш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 32 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта).
2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 29 мартыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы рәсми сайтында, Сармаш-Баш авыл җирлегенең Сармаш-Баш авылы, Федоровка авылы, Кәдек авылы торак пунктлары территорияләрендә түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

Сармаш-Баш ав., Октябрь ур., 66 й.;
Федоровка ав., Күпер ур., 14 й.;
Кәдек ав., Елга ур., 4 й.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Муниципаль берәмлек башлыгы,**
**Совет Рәисе** **Р.М.Фәсхетдинов**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге Советының 2025 елның 24 мартындагы 135 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы депутатлары сайлаулар уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы**

**1 нче бермандатлы Октябь сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 32

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Сармаш-Баш авылы, Октябрь урамы, №№ 1 – 25 йортлар.

**2 нче бермандатлы Елга сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 36

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Сармаш-Баш авылы, Октябрь урамы, №№ 27-49 йортлар.

**3 нче бермандатлы Урман сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 34

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Сармаш-Баш авылы, Октябрь урамы, №№ 50-79 йортлар.

**4 нче Мәктәп бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 31

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Сармаш-Баш авылы, Октябрь урамы, №№ 80-95 йортлар, Үзәк урамы, №№ 104-112 йорлар.

**5 нче Үзәк бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 36

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Сармаш-Баш авылы, Үзәк урамы, №№ 97/1-103/2 йортлар .

**6 нчы Басу бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 32

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Федоровка авылы, Күпер урамы, №№ 18-23 йортлар, Басу урамы, №№ 35-39 йортлар , Клкб урамы №№ 23-45, Сармаш-Баш авылы,Үзәк урам №№96/1-96/2 йортлар.

**7 нче Кояш бермандатлы сайлау округы**

Сайлаучылар саны – 30

Округка Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге территориясенең бер өлеше керә: Кәдек авылы, Клуб урамы, Елга урамы: Федоровка авылы Кояшлы урамы №№ 1 – 9, Басу урамы №33 йорты.

## Округлар схемасының график сурәте

